РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

19 май 2026 ел Буа шәһәре № 2-12

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламенты турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2014 елның 12 ноябрендәге 4-42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (28.12.2024 редакциясендә), «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (10.04.2025 редакциясендә) һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставының 21 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды :

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламенты турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2014 елның 12 ноябрендәге 4-42 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 7.4.2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы
вазифасын башкаручы И.Ф. Еремеев